**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларын раслау турында» 2017 елның 1 февралендәге ПУ-89 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 сентябрендәге ПУ-833 номерлы, 2018 елның 25 гыйнварындагы ПУ-91 номерлы һәм 2019 елның 19 декабрендәге ПУ-779 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Таһиров Марсель Шәрипҗан улын – «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең аерымланган структур бүлекчәсе – Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты җитәкчесен (килешү буенча);»;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гыйсмәтов Радик Расыйх улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасарын;»;

в) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 18 ноябрь
№ ПУ-763